# Таң алдыннан сүнде шәм...

***Шагыйрь Фәннур Сафин тууга 75 ел***



*Фәннур Шәйхенур улы Сафин – шагыйрь, 1948 елның 27 июнендә Минзәлә районы Күзкәй авылында туа. 1969-1974 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. Ф.Сафин әдәбиятка бик яшьли килә, мәктәптә укыганда ук беренче шигырьләре белән «Ялкын» журналы һәм «Яшь ленинчы» газетасында күренә башлый. «Кеше юлга чыкса», «Сез кемнәр?», «Тынлык», «Күкчәчәк», «Чәчәк гомере» исемле шигырь җыентыклары авторы. Ф.Сафинның лирик шигырьләренә күп кенә җырлар иҗат ителә һәм популярлык казана. Шагыйрь 1992 елның декабрь енда Казанда фаҗигале төстә вафат була.*

## Тукай ягы

Күргәнем бар шундый кешеләрне
(Башкаларны болай сагынмам);
Егетләрчә җитди горурланып:
– Без бит, диләр, Тукай ягыннан!

Паспортларга түгел, күңелләргә,
Йөрәкләргә уеп язылган:
Минзәләдән булыйк, я Чаллыдан –
Без барыбер Тукай ягыннан!

Якташларың, Тукай, сине укый...
Бәләкәйдән, бала чагыннан
Күңелләрдә – синең якты җырлар,
Синең моңнар күздә чагылган!..

Күпләр әйтер шуны,
Сорап кара
Идел буе халыкларыннан.
Башны горур чөеп әйтер алар:
– Без, – диярләр, – Тукай каныннан!

## Кош

Мин кош мәллә, әни? Кош бугай шул...
Күңелдә гел очу теләге.
Биекләргә менеп, нурлар җыеп,
Туган җиргә төшү теләге.

Хыял киңлекләрен иңләгән җан
Ваклыкларын җирнең җиңә ул.
Илем өчен биек очам диеп,
Яналмаган йөрәк нигә ул?!

## Кеше юлга чыкса...

Кеше юлга чыкса,
икмәк телеп
калдыра, ди, ишек өстендә.
Аннан инде ничек кайтмый калсын,
аны монда ризыгы көтсен дә!..

Барыр юлым уңа күрсен, дисә,
ниятләре булса изгедән,
юлчы үзе белән
бер уч туфрак
алып китәр туган нигездән.

Юлчыларны илдән халык шулай
йолаларны бозмый озата.
Шуңадырмы, ирләр кайталмаса,
илләр гизеп,
моңлы җыр кайта!

## Яхшылык

Казан күген, Идел киңлекләрен
Сыйпап узган тәсле ак болыт,
Рәнҗүләрне чиста кулы белән
Юып ала икән Яхшылык.

Хыялларга күпме киртә куйдык,
Кирәгеннән артык сак булып.
Матурлыкка матур дип, кинәнеп
Бер соклану үзе Яхшылык.

Ныклык теләп безгә, йөрәк кушкан
Хаклык якларына чакырып,
Таш өстендә борын төртә үлән –
Җирдән безгә дигән Яхшылык.

* * *

Күккә атсам, тияр кошка,
Нигә миңа бу сунар?
Бу мылтыкны нишләтергә?
Аптырадым мин шуңар.

Юк, атасым килми минем
Төлкегә я боланга.
Атсам барып тияр кебек
Үзем узар юлларга.

Тиле ядрә тияр кебек
Халыкларга, илләргә.
Атмыйм дигәч, атмыйм инде
Хәтта көзге җилләргә!..

Шунда әткәй мылтыгын мин
Чормага ук ташладым.
Сүзләр белән Җир сылуның
Рәсемен ясый башладым.

## Игенчегә

Күңелеңдә җиргә кадер-хөрмәт,
Кырны сыйдыралган олы йөрәк.
Яңгыр яумый торса, кырлар түгел,
Синең күңел яна дөрләп-дөрләп.

– Йә, каршы ал!..– диеп, ераклардан
Йөгерәдер алтын дулкыннарың.
Төннәрен дә шулай пышылдашып,
Үзенә дәшә сине мул кырларың.

Читкә китсәң, чит җирләрдә ятып,
Син тыңлыйсың үз кырларың шавын.
Күңелләрең тулы ут булса да,
Кырга чыгып, син көтәсең явым.

## Таңгы шигырь

Таң турында шигырь язды шагыйрь.
Таң алдыннан сүнде шәм...
Шул таңнарны уза алырмынмы,
Яланаяк йөгерсәм?..

Болыннарда кыяк камылларга
Кисә-кисә аякны,
Әй йөгерәм! Житә алырмынмы
Яна таңнарга чаклы?!

Ялкынланып шулай без барабыз,
Таңнан таңга үтәбез.
Сизмибез дә: янар яшьлектән соң
Алтынланып житә көз.

Ә без – һаман алга!
Бу тормыштан
Таба-таба ләззәт, тәм.
Һәм ал таңда яңа шигырь туа...
...Таң алдыннан сүнә шәм...

## Үзән

Тау тау инде, ә без үзәннәр...
Тик таулар да үзән чагында
Калыкканга кадәр түзгәннәр...

Яшәешкә хәйран кылырлык...
Тауда була таулар түземе,
Үзәннәрдә булган сабырлык...

Гөлләр кайный жилдә, тибрәнә!..
Иркәләгән кебек сабыен,
Тауны тота үзән иңнәрдә...

Йоклый үзән яшелен ябынып...
Туганына дәшкән шикелле,
Офыкларга ала кагылып...

Илаһиат монда, аппагым!..
Мондый якты, мондый матурлык,
Мондый ыру кайда бар тагын?!

## Тракторлар гөрли...

Тракторлар гөрли, тракторлар...
Бераз моңсу...
Бераз күңелле!
Тракторда ядан кайталмаган
Тракторчы улы түгелме?!

Тракторлар гөрли, тракторлар...
Ул жир сөрә төне буена.
Ерак офыклардан әтисе дә
Кайтып килер төсле тоела...

Тракторлар гөрли, тракторлар...
Юллар кебек...
Ера-а-ак буразна...
Кулларыңны куй да каш өстенә
Карап торчы,
Туктап беразга?!

## Дөнья...

Кемдер дәшми шәһит китә,
Тугры калыр өчен.
Кемдер яши, тугры сүзне
Ярып салыр өчен.

Кемдер яши, тыныч кына
Гомер үтсен диеп.
Яки минем алда дөнья
Тезен чүксен диеп.

Кемдер яши «сөям...» дигән
Бердәнбере өчен.
Һәм кемгәдер күкрәгеннән
Ялкын өрер өчен...

Шул кемнәрдер өчен бу жир
Борчыла, сөенә.
...Бер карадан киенә ул,
Бер актан киенә...

* * *

Нинди тормышчан сүз — «яшәү»,
Никадәр табигыйлек.
Нинди, нинди рәхәт яшәү
Назланып та сөелеп.

Кояшның һәр нурындагы
Җылыны җыеп җанга,
Иң кайнар сүзләр пышылдап,
Мин киләм синең алга.

Мин алдан ук, алдан уйлыйм
Назланып туймасыңны.
Нишлим, очрашканчы шулай
Күңелгә уйгач инде?..

Синең елмаюың хәтта
Үзе яшәү, мең саулык.
Иңнәреңдә дөрли, яна
Җилдәй йомшак ак яулык.

Атлыйсың, сөлектәй сылу!
Һәр керфегең бер очкын.
Мондый матурлыгың өчен
Нишләтим сине, дустым?

Йолдыз итеп чөяр идем,
Кызганам бит мин сине.
Көнләштерә җирнең хәтта
Үлән селкетер җиле!

Синең белән очу өчен
Кагынырга куркам мин.
Иренеңә түгел, кулыңа
Кагылырга куркам мин.

Ә шатлыкның юк чикләре,
Гүя синдә дәвамым...
Юкса, сине тик хыялда
Назладым һәм ...назландым.

## Кайту

Тагын өйгә! Туган якка!
– Мин сине көттем,
Көт-те-ем! –
Дигән кебек, өй өстендә
Бии күгелҗем төтен!

## Авылым

Җил тарата монда гөлләр исен,
Бураларда — нарат бүрәнә.
Кыңгыраулы атлар үтеп китте,
Яшьтәшләрем, димәк, өйләнә!

Яшь кияүләр ашыга кыз куенына,
Сабыр кызлар көтә туй көнен.
Картлар акыл бирә:
– Ни дисәң дә,
Ялгыз – ялгыз инде ул, энем...

...Илбасар да килде, юлбасар да,
Калдырмам, дип, берни маяга.
Ярый әле, шундый чакларында
Ил халыклар иңенә таяна...

Урамнарда хәзер сирень исе,
Бураларда – нарат бүрәнә.
Җир йөзендә ялгыз калмас өчен
Яшьтәшләрем бүген өйләнә!

## Моң

Җан иң әүвәл тотып алган бер көй
Китми икән, китми хәтердән.
Йөрәк каны аша бөтен тәнгә
Тарата җан аны кадерләп.

Сикереп төшә хәтер уртасына;
Олы бәйге — Сабан туена.
Биергә дип чыккан чая кыздай,
Тынгы бирми моң төн буена.

Тынгы бирми, димәк, яши миндә
Һәм чакыра туган ягыма.
Туган якта калган бала чакка
Чакырып ул җанга кагыла.

Туган телдә бер сүз ишетсәм дә,
Шул моң миндә кинәт яңара.
Дәрт өсти ул җаным учагына,
Килер бәхет өчен янарга.

Бәхет исә ерак түгел безгә,
Яралган ул көнем-төнемнән.
Аермаган кебек ул илемнән,
Аермасын туган телемнән.

## Заман җиле

Куалый җил, ашыктыра,
Әйдәгәндәй заманны.
– Мәйданга! – дип сыйпап уза,
Бәйләгәндәй яраңны.

Корыган талда сызгыра, –
Табигатькә ишарә:
«Яшел шатлык-юанычың
Китеп бара ич әнә!..»

Тик гамьсезгә нәрсә аңа –
Килгән ни дә киткән ни.
...Әй, бу заман җилләре дә
Акыллырак микәнни?!

## Күңелдә

Җан түрендә ак бураннар,
Тагын нидер бар кебек...
Көннәр җепкә асылып язга
Кергән мамык кар кебек...

Алмагачлар шау чәчәктә!
Ә күңелдә – кар иле...
Ник очрашкан көндә, сылу,
Калдырып киттең мине?!

## Сез кемнәр?

Сез кемнәр, сез кемнәр, сез кемнәр?
Сихерле киртәме юлларда?
Томаннар аша без үреләбез
Күрешергә сузылган кулларга.

Абынган, егылган чак була,
Барысын аңлыйсыз, күрәсез.
Ялына ут капкан толпардан
Кул сузып төшләргә керәсез.

Ничәмә мәртәбә бит инде
Киләчәк өчен сез янасыз!..
Без юлга чыкканда,
Кул болгап,
Ялкыннар эчендә каласыз!..

...Шартлаулар, янгыннар яктыртса,
Барыбер караңгы ул төннәр...
Шул төндә яндыгыз, туганнар,
Менә бит сез кемнәр, сез кемнәр...

Янды тән, янды кан – җан калды,
Шуңамы якты бу ак көннәр?
Һәм шуңа ни булыр җавабың? –
Без кемнәр, без кемнәр, без кемнәр?!

Зур серләр ачсак та – без кемнәр?
Галәмгә очсак та – шул сорау!
Илләрдән китсәк тә, кайтсак та,
Ярларны кочсак та – шул сорау!..

...Төшләргә керәсез, күрәсез:
Шул юлда безнең дә гомерләр.
Меңләгән күз карый бу чорга:
– Сез кемнәр, сез кемнәр?
Сез кемнәр?!